**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының**
**Урта Комар авыл җирлеге башлыгы**

# КАРАРЫ

**15 ноябрь, 2024 ел** **№6**

**Кукмара муниципаль районы Урта Комар авыл җирлеге Студеный Ключ авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кукмара муниципаль районы Урта Комар авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2024 елның 28 ноябрендә 16 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Урта Комар авыл җирлегенең Студеный Ключ авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Урта Комар авылы, Май урамы, 1Г йорты адресында урнашкан мәдәният йорты бинасында уздырырга.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Сез 2025 елда Кукмара муниципаль районының Урта Комар авыл җирлеге Студеный Ключ авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан; локаль сугышларда һәм Украинада махсус операция барышында һәлак булганнарның гаиләләреннән; 80 яшькә җиткән һәм аннан да өлкәнрәк затлардан кала, 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (Студеный Ключ авылындагы чишмәләрне ремонтлау, карап тоту, төзекләндерү, култыксалы баскычлар урнаштыру, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, Студеный Ключ авылы чишмәләрен төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре);

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмалары төзү һәм ремонтлау (су белән тәэмин итү челтәрләрен, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру, материаллар сатып алу, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, Студеный Ключ авылын су белән тәэмин итүне, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту буенча башка эш төрләре);

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Студеный Ключ авылына янгын гидрантлары сатып алу, ремонтлау һәм урнаштыру һәм янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү буенча башка эш төрләре)

- традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү (Студеный Ключ авылы зираты территориясен төзекләндерү һәм карап тоту, материал сатып алу һәм урнаштыру, коймаларны ремонтлау, инвентарь сатып алу, зират территориясен төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре)

- торак пункт территориясен төзекләндерү
(Студеный Ключ авылы спорт мәйданчыгын төзү, карап тоту, төзекләндерү, җиһазлау, инвентарь, җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, спорт мәйданчыгын төзү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Студеный Ключ авылында урам-юл челтәрен карап тоту, юлларга вак таш салып төзү, ремонтлау һәм төзекләндерү, ягулык-майлау материаллары һәм МТЗ тракторына комплектлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, Урта Комар авылында юлларны карап тоту буенча башка эш төрләре);

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (Студеный Ключ авылында урам яктыртуны карап тоту, комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре);

- яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру һәм Студеный Ключ авылының яр буе зоналарын, сулыкларын чистарту буенча башка эш төрләре)

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары составына кермәгән җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру Студеный Ключ авылының җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өстендәге кичүләрне ремонтлау буенча башка эш төрләре)

- каты көнкүреш калдыкларын туплау мәйданчыкларын төзү, каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, каты көнкүреш калдыклары өчен мәйданчыклар төзү һәм рөхсәтсез чүплекләрне бетерү буенча башка эшләрне гамәлгә ашыру)

- тукталыш комплексларын ремонтлау, сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру Студеный Ключ авылының тукталыш комплексларын ремонтлау, сатып алу һәм урнаштыру буенча башка эш төрләре)

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Урта Комар авылы башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Урта Комар авыл җирлеге башлыгы — С.В. Федоров

ОГРН 1021607752891
ИНН 1623001660